СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Әгерҗе шәһәре № 47-16

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шәһәр төзелеше һәм инвестицион эшчәнлекне, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, муниципаль берәмлекнең икътисадый үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 10, 18 һәм 21 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Сетевая компания» ААҖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеге турында» 2019 елның 22 маендагы 37-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын ясарга әзерләнергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына «Сетевая компания» ААҖ энергетика объектларын чагылдыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 22 маендагы 37-7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 7 абзац белән тулыландырырга:

«-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориаль планлаштыру схемасына Әгерҗе муниципаль районы электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү өлешендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын әзерләргә;».

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 8 абзац белән тулыландырырга:

«-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе муниципаль районын электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материаллар эшләү өлешендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын әзерләү буенча аны үтәү сроклары белән чаралар планын расларга (кушымта итеп бирелә).».

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын https://fgistp.economy.gov.ru веб-адрес буенча территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә һәм эшкуарлыкка ярдәм буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.Т. НУРИСЛАМОВ

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының «29» 05 2020 ел, № 47-16
карары белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе муниципаль районын электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материаллар эшләү өлешендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын әзерләү буенча аны үтәү сроклары белән чаралар планы**

| № п/п | Чаралар исеме | Чараларны үтәү сроклары | Җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1. | Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан техник биремне раслау.<br>Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районын электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материаллар эшләү өлешендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын әзерләү буенча 3 яклы контрактны төзү | 2020 елның май-июне | |
| 2. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын Әгерҗе муниципаль районының электр белән тәэмин итү картасының территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материалларны эшләү өлешендә территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыру: https://fgistp.economy.gov.ru | Проектны эшләүче тарафыннан җибәргәннән соң 5 эш көне эчендә | |
| 3. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына Әгерҗе муниципаль районының электр белән тәэмин | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының территориаль планлаштыру | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итү картасының территориаль планлаштыру схемасын нигезләү буенча материаллар эшләү өлешендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын раслау | схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектына уңай бәяләмә кабул ителгәннән соң бер ай эчендә | |